ГЛАВА ДЫМ-ТАМАКСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

с.Дым-Тамак, ул.Ленина, д.1а, , 423955

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ДИМТАМАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

Димтамак авылы, Ленин урамы, 1а йорт,
423955

Тел.:(85593) 4-52-37, факс:4-52-37, e-mail: Dtam.Utz @tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

№ 3 25 сентябрь 2020 ел

2020 елның 3 июнендәге Димтамак авыл җирлеге башлыгының 2 санлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Димтамак авыл җирлеге җирле үзидарә органнарына гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә анализ үткәрү тәртибе турында»

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ санлы, 2006 елның 2 маендагы «Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 59-ФЗ санлы Федераль законнар, 2003 елның 12 маендагы «Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында» 16-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә

карар бирәм:

1.2020 елның 3 июнендәге Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Димтамак авыл җирлеге башлыгының 2 санлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Димтамак авыл җирлеге җирле үзидарә органнарына гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә анализ үткәрү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 4 бүлектә «ел саен» сүзен «һәрдаим» (әмма елына бер тапкырдан да ким булмаган күләмдә) дип алмаштырырга;

- 5 һәм 8 бүлекләрдә «хисап чорыннан соң килүче» сүзләрен «киләсе хисап елы» дигән сүзләргә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен үз контролемдә тотам.

Димтамак авыл җирлеге башлыгы урынбасары Ф.М.Гәрипов